**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Кыр Тәүгелдесе авылында гражданнар җыены карары**

11 ноябрь 2024 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Кыр Тәүгелдесе авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елда Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Кыр Тәүгелдесе авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Кыр Тәүгелдесе авылында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга (юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу) юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Яңа Чәчкап авыл җирлегенең Кыр Тәүгелдесе авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Яңа Чәчкап авыл җирлеге башлыгы _________ Д.Д.Абдрахманова

Халык җыены секретаре _________ М.Г. Йосыпова